ФОМА УРТА ГОМУМИ БЕЛЕМ МӘКТӘБЕ УКУЧЫЛАРЫНЫҢ АЙЛЫК ГАЗЕТАСЫ

# «КӨЗГЕ»

ГЫЙНВАР, 2018

№5 (35)

**ҮЗЕҢ НИНДИ, КӨЗГЕҢ ШУНДЫЙ!!!**







**11— Халыкара “РӘХМӘТ” көне**

**25—Студентлар көне**

## КАНИКУЛДА ДА ИМТИХАННАРГА ӘЗЕРЛЕК БАРДЫ.



Бөтен дөньяны ап-ак кар каплады. Табигать җем-җем итеп торган яңа матур күлмәген киде. Агачлар да җылы мамык шәлләрен ябынды. Елгалар, күлләр көзге кебек шома боз белән капланды. Урман-кырлар өстендә тантаналы тынлык. Кыш көне көннәр кыска, салкын.Балалар көтеп алган каникулда рәхәтләнеп чаңгычанада, тимераякта шуа. Шул арада мәктәптә ТДИ һәм БДИ га әзерлек эшләре тулы куәт белән бара. Укытучылар Сафиуллин Халим Салихович,Ситдикова Клара Касыймовна, Абдрахманов Рәис Азатович, Тарасова Снежанна Анатольевна, Фахреева Гөлфия Якубовна расписание нигезендә экзаменга әзерлекне алып баралар. Ә балалар, каникулда булсалар да укуның кирәклеген хуп күреп, укытучыларының һәр әйткән сүзен йотлыгып тыңлап, зиһеннәренә салырга тырышалар.

## Кышкы ялымның бер көне

Менә сагынып көтеп алган кышкы каникуллар да килеп житте. Ап-ак, ябалак кар яуды. Балаларга шатлык өстәп Кыш бабай тәмле күчтәнәчләрен өләште.Матур кулмәген киеп матур итеп бизәнеп чыршысылукай да кунакка килде.

Кышкы кояшлы көнне без дуслар белән урамга чыктык .Бергәләп Кар бабай ясадык . Түгәрәк кар шарларын берсе өстенә икенчесен куярга шактый тырыштык .Тирә куршеләр безне күзәтеп тордылар .Узләренең балачакларын искә төшереп ,безгә чыгып ярдәм иттеләр . Кар бабайга куңелсез булмасын өчен янәшәсенә Кар кызы да ясап куйдык.Аннан соң Кар бабай һәм Кар кызы янында истәлеккә фотога төштек. Менә шулай сиздермичә дә үтте дә китте кышкы каникуллар.Безнең өчен кызык һәм файдалы, хәтеребездә гомерлеккә уелып калырлык истәлекле вакыйгаларга бай булды ул. Киләсе каникулларны да шулай уңышлы һәм файдалы үткәрергә насыйп булсын дигән теләктә калабыз. **Масгутова Гөлназ**

**Бу санда:**

Каникулда да имтиханнарга әзерлек барды 1
Олимпиадада уңышлар 2
Якыннан танышыйк! 3
Тау шууның үз тәртибе 4
Укучылар иҗаты 5
БДИ- 2018 6
Котлыйбыз! 7



Наш долгожданный каток готов!!! Сегодня в такой солнечный и морозный день провели акцию "Спорт - альтернатива пагубным привычкам". Дети с удовольствием катались и радовались, остались довольны. Скоро начнется  школьный турнир по хоккею.




19 января 2018 г. в 12.00 - 13.30 пройдёт Республиканское родительское интернет-собрание "Виртуальная жизнь ребёнка: Интернет-друг или враг?"



26 январь көнне “ Сагынып кайттым сине мәктәбем исеме астында  студентлар белән очрашу узды-рылды. Очрашуда 8-11 сыйныф укучылары, укытучылар катнашты.Беренче өлештә студентлар белән әңгәмә , җанлы сөйләшү , икенче өлешендә 11 сыйныф укучылары белән студентлар арасында “Тапкырлар бәйгесе” булды, ә өченче өлеш чәй табыны артында дәвам итте. Һәр сыйныфта бу очрашуга әзерлек белән килгән иделәр.Кичә матур җырлар, дәртле биюләр белән бәйләнеп барды.



## Олимпиада — тырыш һәм сәләтлеләр бәйгесе

Ниһаять, район олимпиадалары да тәмамланды. Безнең мәктәп укучылары да үзләрен тиешле дәрәҗәдә күрсәтте . Ә иң күңеллесе, район күләмендә  БЕРЕНЧЕ урын бездә бит! Афәрин! Республика күләмендә дә укучыларыбыз Гафурова Алия, Зарипова Зилә сынатмаслар. Районыбыз данын яклаган укучыларыбызга ныклы сәламәтлек, яңа уңышлар теләп калабыз!

Уңышлар сезгә, кызлар!

**Зачем нужна олимпиада?**

«Благословенны трудности, ибо ими растём», – сказал некогда Николай Константинович Рерих. Олимпиада как вид состязания известна с ещё незапамятных времён. Причём не только её спортивное направление, но «умственные состязания». В чём же состоит польза таких интеллектуальных боёв, есть ли супер действенные способы подготовки и что в принципе влияет на результат? Предметные олимпиады  – это состязание учащихся (при этом не всегда только средне-образовательных учреждений), в котором участники демонстрируют свои навыки и знания по определённым дисциплинам. Началом современного олимпиадного движения в России принято считать олимпиаду по математике в  1934 году, организованную Ленинградским университетом.Сегодня в России в среднем в год проводится около 70 олимпиад различных масштабов и уровней. Так что же даёт участие или победа в олимпиаде? В первую очередь, развитие интеллектуальных способностей. Кроме того, участие в олимпиадах не только расширяет кругозор и улучшает абстрактное и логическое мышление, но и совершенствует творческие способности.Всем известно, что олимпиадные задания не стандартны, следовательно, у участников ум приспосабливается к «гибкости», оригинальности разработки идей. В будущем это поможет нынешним школьникам решать различные, в том числе и бытовые, жизненные, задачи намного лучше, так как уже с юных лет они научатся смотреть на задачи с разных сторон и рассматривать их под разным углом. Ещё одним важным моментом является способность правильно применить знания. Ведь одно дело просто выучить материал, другое – понимать, как и где его можно использовать. Решение олимпиадных заданий отлично тренирует ту самую нестандартность мышления, гибкость ума, возможность применять полученные и усвоенные знания в самых разных сферах.Участие в олимпиадах в некотором смысле развивает уверенность в себе, повышает стрессоустойчивость. Ведь как бы там  ни было, олимпиада – это своего рода стресс, и способность перебороть его. Участие в предметной олимпиаде – саморазвитие ученика.

# Якыннан танышыйк!






**Укучыларның сорауларына татар теле һәм әдәбияты укытучысы Әһлиуллина Гөлүсә Дамир кызы җавап бирә.**

- Укытучы һөнәре нәрсәсе белән үзенә җәлеп итте?

- Балаларны яраттым.

-Мәктәптә Сезнең яраткан предметыгыз нинди иде?

- Математика.

- Яраткан укытучыгыз кем иде?

- Башлангыч сыйныф укытучысы Гайфуллина Роза Абдулловна.

- Начар билге алганыгызны хәтерлисезме?

- Хәтерләмим. Тик мәктәптән куып җибәргәч кенә өйгә кайтканыбыз хәтердә нык уелып калган. Мәктәпне ярата идем.

- Республика олимпиадаларында ел саен җиңү яулау җиңел бирелмидер. Сере белән уртаклашыгыз әле.

- Беренчедән укытучы эшләрне бәяләү критерияләрен бик әйбәт белергә тиеш, икенчедән баланы яратырга, аларның алган белемнәрен тагын да тирәнәйтү өстендә эшләргә. Бигрәк тә балаларның классташларыннан аерылыбрак торганнары белән эшләргә яратам, аларның үзүзләренә ышанычларын арттыру өстендә эшлим.

- Сездә шигырь язу сәләте бар. Аны сез кайчан сиздегез?

- Беренче шигырем Бөек Ватан сугышында җиңеп кайтучылар турында иде. Аны «Яшь ленинчы" газетасына юлладым. Инде һәр газетаны түземсезлек белән көтә башладым. Тик шигырем юк. Беркөнне зур конверт килеп төште. Анда тырышканың өчен рәхмәт, тик әле шигырь язу өчен шомарырга кирәк дигән иделәр. Шуннан кәефем төшкән иде. Башлангычта укыта башлагач шигырьләрне тагын яза башладым. Алар инде эш өчен кирәк иде. Мин аларны ак кәгазьгә карандаш белән язарга яратам.

- Сезнең яраткан әсәрләрегез?


- Кечкенә чакта Гариф Гобәйнең «Маякчы кызы» әсәрен кат– кат укый идем. Хәзер М.Мәһдиев, Х.Туфанны укыйм. Бүгенге көн язучыларыннан үзебезнең С.Хәйруллина, Ф.Мөхәммәтова шигырьләрен яратып укыйм.

- Укучыларга һәм укытучыларга теләкләрегез?

- Бүгенге заман укытучысына көч, сабырлык, түземлекләр телəп калам. Ә укучылар белгә өчен укымасыннар, тормыш итәрлек белем алсыннар, иң мөһиме кешелек сыйфатларын югалтмасыннар.

**Әңгәмәне «Яшь журналистлар" төркеме алып барды.**

## «Шәһри Казан» нан файдалы киңәшләр




Бармак озынлыгы сезнең турыда нәрсәләр сөйли? А) Имән бармак атсыз бармактан кечкенәрәк. Мондый бармак ияләре белән аралашу рәхәт, тәвәккәлләр, проблемаларны тиз һәм җиңел хәл итәләр, кешенең хәленә керә беләләр. Алардан яхшы инженер, галим чыга...

В) Имән бармак атсыз бармактан юк-барга борчыганнарын сөймиләр. Бу кешеләр...

Бармак озынлыгы сезнең турыда нәрсәләр сөйли?

А) Имән бармак атсыз бармактан кечкенәрәк. Мондый бармак ияләре белән аралашу рәхәт, тәвәккәлләр, проблемаларны тиз һәм җиңел хәл итәләр, кешенең хәленә керә беләләр. Алардан яхшы инженер, галим чыга.

В) Имән бармак атсыз бармактан озынрак. Алар тынычлвк яраталар, юк-барга борчыганнарын сөймиләр. Бу кешеләр беренче булып адым ясамый, шулай игътибарны бәяли беләләр.

С) Имән бармак белән атсыз бармак бертөсле. Мондый кешеләр бәхәсләшергә яратмый, сабырлар, бөтен кеше белән дә бертигез аралашалар. Тугрылар, үз эшләренә бирелгәннәр.

*Мәгълумат интернет челтәреннән алынды*

## Тау шууның үз тәртибе




### Табиблар чаң суга

«Тюбингларны тыярга кирәк», - дип белдерде Татарстан травматологлары. Бу— быел республика хастаханәләренең травматология бүлекләрендә тау шуганда җәрәхәтләнгән пациентлар артуы белән бәйле.

- Кышкы каникуллар чорында гына да Казанда 10 лап кеше хастаханәгә эләкте, аларга катлаулы операцияләр ясалды. Ә җәрәхәтләнеп өй шартларында дәвалванучылар никадәр - дип сөйләде Казанның 7 нче клиник хастаханәсе травматолог - ортопеды Андрей Лодвиков.
- Табиб әйтүенчә, балалар, гадәттә, тау шуарга яраклаштырылмаган урыннарда имгәнә. Ә андый урыннар бик күп.
- **Ничек сакланырга?**
- Шунысын әйтергә кирәк: табиблар үтенеченә карамастан, тюбингларны тыю мөмкин эш түгел. Ник дигәндә, алар өчен ГОСТ таләпләре юк.
- Әмма тау шуу урыннары өчен ГОСТ таләпләре бар бит. Мәсәлән, тау чаңгысы трассалары өчен алар 2015 елдан гамәлдә.
- Казандагы тау чаңгысы комплексларының берсендә әйтүләренчә, алар чаңгычыларга билгеләнгән тауны кебек үк, тюбингта шуу урыннарын да махсус җиһазландыра: мәгълүмати билгеләр - күрсәткечләр, кисәтүче һәм тыючы калканнар куя, куркыныч объектлар койма белән әйләндереп алына. Трассаны тигезли торган махсус трактор эшләп тора.
- Дәүләт стандартлары кирәклеген РФ парламенты депутаты Ирек Зиннуров та хуплады. Ул кешеләргә теләсә кайда тюбингта шуу куркыныч икәнен аңлату, кисәтүче күрсәткечләр урнаштырырга кирәклеген билгеләп үтте.

Мәгълүмат “Дуслык” газетасыннан алынды.

# Укучылар иҗаты







Аглиуллина Әлинә фотолары, 11 нче сыйныф

**Безопасный отражатель.**

Если ты спешишь куда-то?
То по трассе не иди...
Лучше светоотражатель
На рюкзак свой прикрепи!

Вот теперь ты без сомненья
Хоть куда можешь пойти.
Только знай, что безопасность -
Лучший друг твоей семьи!

Аглетдинова Гулляр, 6 класс

# Конкурслар! Конкурслар!



Нурлат районы «Балалар иҗат үзәге»нең 30 нчы гыйнвар приказы нигезендә «Десятая муза» һәм «Юность России» конкурсларына нәтиҗә ясалды. «Десятая муза» конкурсының «Документальный фильм» номинациясендә 10 нчы сыйныф укучысы Аглиуллин Аяз (җитәкчесе Аглиуллина Г.Д.) җиңүче булды.

«Юность России» конкурсының “Серия” номинациясендә 11 нче сыйныф укучысы Аглиуллина Алина 2нче призлы урынны, ә «Эксперимент» номинациясендә шул ук укучыбыз 3 нче призлы урынны яулады. «Серия » номинациясендә 3 нче сыйныф укучысы Галлямова Әдилә сертификат белән бүләкләнде.



. 27 нче декабрь числосы белән 9 нчы номерлы протокол нигезендә «Үзеңнең тавыш -2018» («Свой голос-2018») мәктәп газеталарының республика конкурсы муниципаль этабы нәтиҗәсе билгеле булды. Безнең мәктәпнең «Көзге» гәҗите районда «Авыл мәктәпләренең иң яхшы газетасы» номинациясендә икенче призлы урынга лаек булды . Шунысы кызыклы 12 мәктәп арасында бер безнең мәктәпнең татар телендә бастырылган эше призлы урынга лаек булган. Бу уңышыбыз газетаның редколлегия әгъзаларының тырыш хезмәте нәтиҗәсе. Аларга иҗади эшләрендә уңышлар телибез.



Әле 1 нче сыйныфта гына укысалар да беренчеләр укуда да , төрле конкурсларда да сынатмыйларын үзләрен
Хайбуллина Фатима республика конкурсының муниципаль этабында «Юные дарования» конкурсының «Бу гаҗәеп дөнья» ( “Этот красочный мир») номинациясендә 2 нче призлы урынга лаек булды.
Валиуллин Нияз (1 нче сыйныф) белән Аглетдинова Гөлләр ( 6 нчы сыйныф укучысы) «Хәрәкәтнең яшь инспекторлары» конкурсында катнашу бәхетенә ирештеләр. Аларның эшләре «Йөрәгемне бирәм балаларга» район бәйгесендә күргәзмәгә куелганнар иде.

## БДИ-2018: үзгәрешләр дәвам итә

**Информатика**.Программа мисалларының кайбер өлеше Си теленнән С++ теленә күчерелгән.**Рус теле**.Лексик нормаларны белүгә багышланган бирем өстәлгән. Хәзер сөйләм хатасын табып, аны дөресләргә кирәк булачак. **Рус әдәбияты**.Максималь балл 42дән 57гә җитте. Төрле инша өчен төрле балл алырга мөмкин. Мисал өчен 8нче һәм 15нче биремдәге иншалар өчен – 5, ә 9 һәм 16нчы биремнәр өчен хәзер 10ар балл алып була (элек бары тик 4 кенә булган).17нче иншада дүртенче тема кертелгән. Хәзер анда яңача әдәбият турында язарга була. Ләкин быел иншалардагы сөйләм хаталары ясап, әз балл алырга мөмкин.Элек бу исәпкә алынмаган булган. **Физика**.Элек максималь балл 50 булса, хәзер – 52. Астрофизика буенча тагын бер бирем өстәгәннәр. Физика буенча имтиханга дүрт яңа тема кертелгән: электр зарядны саклау законы, конденсатор, дымлылык җитештерүчәнлеге, махсус чагыштырмалылык теориясе нигезләре. Имтиханга әзерләнү буенча пособиеләрдә бу темалар бирелмәгән. Шуңа күрә аерым хәзерләнергә туры киләчәк. **Җәмгыять белеме**.Максималь балл: элек 62 булса, хәзер – 64. 29нчы бирем таләпләрен төгәлләштергәннәр. Бер ел элек кебек, теоретик аргументларга 2 балл бирелә. Тик хәзер мәсьәләне теория ягыннан аңлатсаң, анда төшенчәләр, теоретик нигезләр генә түгел, аңлатмасы да булырга тиеш. Формулировкаларны да төгәлләштерергә кирәк. Хәзер укучы фикер йөртүдә хаталары булмаса, өстәмә балл алырга мөмкин. **Химия**.30нчы номерлы бирем барлыкка килгән. Анда чылбырлар («цепочка превращений») урынына тигезләмә (уравнение) төзергә кирәк. 30 һәм 31 биремнәр өчен хәзер икешәр балл алып була. Эшнең беренче өлешендә балл бирү системасын үзгәрттеләр.  Максималь балл : 60 балл.

**БДИ да укучылар тупларга тиешле минималь баллар күләме узган елдагы кебек кала. Укучыларга рус теленнән, ким дигәндә – 36, рус әдәбиятыннан-57, профиль дәрәҗәдәге математикадан – 27, физика-52, химия –60 һәм биологиядән -36, информатика һәм мәгълүмати – коммуникацион технологияләр буенча иң киме – 40, тарихтан һәм рус әдәбиятыннан – 32, географиядән – 37, җәмгыять белеменнән – 64, чит телләрдән 22 балл җыярга кирәк.**

**Бердәм дәүләт имтиханының төп дулкыны 28 нче майдан 20 нче июньгә кадәр узар дип көтелә.**



“Яшь инспекторлар хәрәкәте”отряды 2017-2018 нче уку елы планы нигезендә гыйнвар аенда «Көйләүче сигналы» темасы буенча белемнәрен күрсәттеләр.Балалар үзләре көйләүче булып төрле уеннар уйнадылар, шул рәвешле алар алган белемнәрен ныгыттылар.

«Юл билгеләре белгечләре» темасы буенча башлангычлар белән яңа материал өйрәнелде, уеннар оештырылды, шигырьләр сөйләнелде. Бу кагыйдәләр балаларның белемнәрен арттырды, алар үзләрен чын шофёрлар итеп хис иттеләр.




**В Татарстане будут проходить всероссийская акция «День сдачи ЕГЭ родителями». В Нурлате 5 марта будут участвовать 15 родителей. Взрослым представляется возможность узнать и прочувствовать на себе, как дети сдают экзамены. В частности - по русскому языку.**



19 нчы гыйнвар көнне мәктәбебезгә район мәгариф бүлеге каршында эшләүче ППМС үзәктән психологлар килде . Алар укучылар белән шәхси консультацияләр,төрле тренинглар, 9,11 сыйныф укучылары өчен “ОГЭ, ЕГЭ га психологик әзерлек” һәм 1нче класска керүчеләрнең мәктәпкә әзерлеген өйрәнделәр.

### Игелек кылу рәхәт!

Педагог - оештыручы Фәхретдинова Равидә Нәгыймовна һәм озайтылган көн группасы җитәкчесе Галлямова Гөлүсә Фоадовна белән берлектә, авылыбыздагы әби-бабайларга кочебездән килгән кадәр ярдәм иттек. Ялгыз яшәүче Гилязова Гөлсем әби белән Минегулова Сәрфия әбиләргә йорт тирәләрен кардан чистартырга булыштык. Мохтаҗларга билгеле бер чаралар узганда гына ярдәмгә ашыкмыйк, ә ел дәвамында ярдәмләшеп яшик. **Игелек кылу рәхәт икән!**






## Гыйнвар аенда туучы кадерле укытучыларыбыз:

## Әхмәтова Рузилә Әсхат кызы, Замалеев Айрат Каим улы,

## Абдрахманов Рәис Азат улы!

Сезне туган көнегез белән чын күңелдән котлыйбыз. Сезгә нык сәламәтлек, күңел тынычлыгы, гаилә шатлыгы, кайгы-хәсрәтсез көннәр, ак бәхетләр, балаларыгызның һәм оныкларыгызның күңел җылысын тоеп, игелекләрен күреп, бәхетле озын гомер кичерүегезне телибез. Киләчәгегез җыр кебек матур, кояш кебек якты булсын. Туачак таңнарыгыз һәрвакыт нурлы, күк йөзегез һәрвакыт аяз булсын.

Гыйнвар аенда туучы
кадерле укучыларыбыз:

Хәлиуллин Инсаф, Стадник Динара, Садртдинов Айдар, Абдрахманова Рәзилә, Хайбуллин Айдар!

Сезнең барыгызны да чын күңелебездән туган көнегез белән тәбрик итәбез. Сезгә укуыгызда зур уңышлар, нык сәламәтлек телибез.

Озын булсын гомерегез,
Тыныч булсын күңелегез.
Бәхет чишмәләрегез мул аксын,
Зур шатлыклар белән таң атсын!

**Бу сан өчен мәктәпнең «Яшь журналист» түгәрәге әгъзалары җаваплы**

**“ К Ө З Г Е ”**

**Директор:** Сафиуллин Хәлим Салихович

***“Фома урта гомуми белем мәктәбе”*** тарафыннан гамәлгә куелды.

(423012 Нурлат районы, Фома авылы, Мәктәп урамы, 18)

Газетага нигез салынды: сентябрь, 2011

Газета уку вакытларында айга бер тапкыр чыга.

Тиражы *чикләнмәгән.*

**Баш мөхәррир**: Фәхретдинова Равидә Нәгыймовна

**Урынбасары:** Аглиуллин Аяз

**Дизайнер**: Гафурова Алия

**Корректор**: Әһлиуллина Гөлүсә Дамировна

**Редколлегия**: Аглетдинова Гөлләр, Гайнуллина Алия, Гайсина Вероника, Закирова Гөлинә, Масгутова Гөлназ, Хайруллина Әдилә, Хисматова Заринә.